**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы**

# КАРАРЫ

**2017 елның «14» июне** **№ 54**

**«Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, тулаем алганда «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге советы карар чыгарды:

1. «Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре» яңа редакциясендә кушымта итеп бирелүчеләр расларга.
2. «Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2011 елның 02 сентябрендәге 26 номерлы, 2012 елның 27 июлендәге 51 номерлы, 2014 елның 11 апрелендәге 116 номерлы, 28.04.2014елның 28 апрелендәге 119 номерлы, 23.10.2014г № 127, 18.10.2016 елның 37 номерлы карарын үз көчләрен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек территориясендә түбәндәге адреслар буенча махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9, Мәдәният йорты бинасы;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мереткозино авылы, Вахитов ур., 9 йорт, авыл китапханәсе мәдәният йорты бинасына урнаша һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыра.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына йөкләргә. .

**Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районының Кече Салтык**
**авыл җирлеге советы рәисе** **А.Г.Җиһаншин**